**Итоговая контрольная работа ( диктант)**
**в рамках промежуточной аттестации**
**по родному (татарскому) языку для 8 класса**

Диктант.

Ипи тәме

Сугыштан соң туган балалар без. Ачлык, сугыш газапларын күрмәдек, шулай да әле безнең буын икмәк кадерен белеп үсте. Әле дә хәтеремдә: ул чакта авыл халкы ташлы тегермәндә он тартты, үзе икмәк пешерде. Әниемнең дә, ап-ак яулык, ак алъяпкыч бәйләп, ипи камырын басуын күзәткәнем бар. Бисмилласын әйтеп кулларын юар, куна тактасына он иләр, камыр басыласы кисмәккә җылымса су салып озаклап камыр басар иде. Камыр тыгызланып кабарып киткәнче, нәзек куллары тәмам талчыкканчы баса ул камырны. Аннары кисмәк өстенә ашъяулык каплап, төнгә мич башына куя. Төне буе йокы керми иде аның күзләренә. Берничә тапкыр торып камыр кабаруын күзәтә. Таң атканчы мичкә ягып, инде өлгереп җиткән камырны кисәкләргә бүлеп, тәмам түгәрәкләнгәнче кулында әвәли, аннан соң он сибелгән тактасына тезә. Мичтәге утын кисәүләрен, тигезләп, мич төбенә тарата. Аннан пумала белән калган күмерләрне җыя, мич төбе тәмам күмер тузаныннан арынгач, түгәрәк камырларны агач көрәк белән мич төбенә тезеп чыга һәм мич авызын калай капкач белән каплап куя. Менә бераздан өйгә хуш исле икмәк исе тарала. *(154 сүз)* *(Д.Гайнетдиновадан)*

Контроль диктантларны бәяләү

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1. | Орфографик һәм пунктуацион хаталары булмаган эшкә<br>Искәрмә. Орфографик (яки пунктуацион) хаталы пөхтә башкарылган эшкә яки бер үк хата бер үк сүзләрдә кабатланса һәм бер пунктуацион хаталы эшкә | «5»ле билгесе куела.<br>«5» ле билгесе куела ала. |
| 2. | 1 орфографик, 1 пунктуацион хатасы булган эшкә<br>Искәрмә. 1 орфографик, 2 пунктуацион хаталы эшкә яки, орфографик хаталары булмыйча, 3 пунктуацион хатасы булган эшкә, яки бер төрдәге 2 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә | «4»ле билгесе куела.<br>«4»ле билгесе куела. |
| 3. | 2 орфографик, 1—3 пунктуацион хаталы, 2 төзәтүле эшкә<br>Искәрмә. 4 пунктуацион, 1 орфографик хаталы эшкә яки бер төрдәге 5 орфографик, 4 пунктуацион хаталы эшкә | «3»ле билгесе куела.<br>«3»ле билгесе куела. |
| 4. | 5 орфографик, 5 пунктуацион хаталы, 4 төзәтүле эшкә | «2»ле билгесе куела. |
| 5. | 6—7 орфографик, 4—5 пунктуацион хаталы, берничә төзәтүле эшкә | «1»ле билгесе куела. |

ОТПРАВИТЕЛЬ
МБОУ "Средняя Общеобразовательная Школа №130 Имени Героя Российской Федерации Майора С.А.Ашихмина"
ПОДПИСАНО
ВЛАДЕЛЕЦ СЕРТИФИКАТА
Самаркина Ирина Николаевна
ДОЛЖНОСТЬ
Директор
СЕРТИФИКАТ
00991280801FAAF15BA3173E5BBA8F1E17
ПОДПИСАН
01.12.2024 14:04:28 МСК
ПОДПИСЬ ВЕРНА

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Вс, 01 дек 2024 14:04:43 МСК
Идентификатор документа 15f6ed4f-9338-445a-a6cc-4621c0663d8f